РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ
«ЛЕНИНОГОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«КАРМАЛКИНСКОЕ
СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»

ул.Геодезическая, д.38а,
с.Мордовская Кармалка,
Лениногорский район, 423298
Тел./факс : (85595) 3-60-59
E-mail: Karmal.Len@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
«КАРМАЛКА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
СОВЕТЫ

Геодезия урамы, 38а йорт,
Мордва Кармалка авылы,
Лениногорск районы, 423298
Тел./факс : (85595) 3-60-59
E-mail: Karmal.Len@tatar.ru


РЕШЕНИЕ КАРАР

2025 елның 17 октябре № 6

«Кармалка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2016 елның 3 октябрендәге 14 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Кармалка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2025 елның 3 октябрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Кармалка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. «Кармалка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2016 елның 3 октябрендәге 14 номерлы (30.05.2017 № 6, 17.11.2017 № 23, 29.01.2018 № 1, 19.09.2018 № 19, 14.12.2018 № 30, 22.01.2019 № 1, 20.03.2019 № 7, 02.10.2019 № 25, 12.02.2020 № 1, 17.06.2020 № 10, 13.08.2020 № 12, 12.11.2020 № 12, 26.03.2021 № 2, 10.08.2021 № 17, 28.04.2023 № 16, 01.08.2023 № 28, 19.10.2023 № 39, 18.12.2023 № 48, 25.04.2024 № 7 04.10.2024 № 20, 18.12.2024 № 27 редакциядә) карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Кармалка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2.6.1 һәм 2.6.2 пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6.1 һөнәри белем дәрәҗәсенә: вазыйфаларның югары, төп һәм әйдәп баручы төркемнәре өчен, шулай ук вазыйфаларның өлкән һәм кече төркемнәре өчен югары белем яки урта һөнәри белем булу;

2.6.2 муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына:

муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары буенча - кимендә бер ел муниципаль хезмәт стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә ике ел эш стажы;

муниципаль хезмәтнең төп вазыйфалары буенча - муниципаль хезмәт яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә бер ел эш стажы.

Әйдәп баручы баручы, өлкән һәм кече төркем муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек буенча эш стажына квалификация таләпләре билгеләнми.

Муниципаль хезмәт стажын билгеләгәндә шулай ук тиешле вазыйфаи төркемнәрнең дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларындагы һәм аларга тиңләштерелгән хәрби хезмәт вазыйфаларындагы һәм башка төр федераль дәүләт хезмәте вазыйфаларындагы эш стажы исәпкә алына.».

2. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы,Лениногорск муниципальрайоны, Кармалка авылы. Геодезия ур., 38а йорт, (административ бина), Нагорная ур., 33 йорт (мәдәният йорты бинасы), Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (https://leninogorsk.tatar.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Лениногорск муниципаль районы
«Кармалка авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе

В.Д.Фатхутдинова